**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6264**
**03.12.2019**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күп фатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 октябрендәге 79-ТРЗ номерлы Законы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 3.18 һәм 5.24 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән (Башкарма комитетның 2017 елның 3 маендагы 2747 номерлы, 2017 елның 28 сентябрендәге 5805 номерлы, 2018 елның 2 августындагы 4343 номерлы, 2019 елның 5 мартындагы 1144 номерлы, 2019 елның 23 маендагы 2663 номерлы, 2019 елның 16 сентябрендәге 4705 номерлы карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре исемлегенә, 25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«25. Төзүченең һәм проект декларациясенең «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында»

2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия» һәм «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы Л.М. Кудряшовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин